# *Шиһабетдин Мәрҗани*




**1818 -1889**

fppt.com

- **Шиһабетдин Мәрҗани** – мәшһүр татар мәгърифәтчесе, фәлсәфәче, тарихчы, дин әһеле, педагог, археолог, этнограф, көнчыгыш халыклар белгече.
- 1818 елның 16 гыйнварында хәзерге Әтнә районы Ябынчы авылында руханилар гаиләсеннән дөньяга килә.

- Шиһабетдиннең әтисе Баһаветдин әл-Мәрҗани заманы өчен алдынгы карашлы һәм төпле белемле шәхес була.




- Шиһабетдин Мәрҗани ун ел укып, әтисе мәдрәсәсен тәмамлаган егет дүрт ел дәвамында Ташкичү мәдрәсәсендә укыта.

- Белемгә сусау аны 1838 елда Бохарага алып килә һәм ул анда төрле мәдрәсәләрдә белемен баета.



- 1843 елда Шиһабетдин Сәмәркандка килеп “Шердар” мәдрәсәсендә укый, тирә-юнь авылларга чыгып, балалар укыта, халык белән аралаша. Ике елдан Бохарага яңадан әйләнеп кайта һәм ул вакытта ук яхшы танылган “Мир гарәп” мәдрәсәсендә белемен янә тирәнәйтә.



1848 елда туган якларына әйләнеп кайта, Казанның беренче мәчетендә имам (мулла) булып тора һәм аның янындагы мәдрәсәдә балалар укыта. Гомеренең ахырына кадәр шунда эшли: руханилык, педагоглык һәм гыйльми-тикшеренү эшләрен бергә үреп бара.

1849 елда Мәрҗани Казан шәһәренең беренче мәчетенә имам һәм аның каршысындагы мәдрәсәгә мөдәррис итеп билгеләнә. Биредә ул үзен бөтенләе белән укыту һәм фән эшенә багышлый, мәдрәсәнең эш тәртибен рәткә салырга һәм анда укыту-тәрбия эшләренең торышын үзгәртергә тырыша.



“Ширдәр” мәдрәсә.
Сәмәркәнд.


•Аның бөтен гомере шәкертләр тәрбияләүгә, гыйлем-мәгърифәт таратуга һәм фәнни эзләнүлбаруга багышланган.

•Ул үз укучыларына шәрекъ шагыйрьләренең һәм фикер ияләренең бай мирасын, татар халкының әдәби ядкарьләрен һәм авыз иҗаты әсәрләрен өйрәтә.

•әр алып.



Шиһабетдин хәзрәт (аны еш кына шулай дип йөртәләр) – энциклопедик галим, күпкырлы шәхес. Аның гыйльми эшчәнлеге күптармаклы: тарих, фәлсәфә, филология, археология, нумизматика, этнография, география, халык иҗаты һ.б. Мәрҗанинең утыздан артык хезмәт язуы мәгълүм.



“Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар” (“Казан һәм Болгар хәлләре турында файдаланылган хәбәрләр”) – Мәрҗанинең иң танылган әсәре. Кыскартылган, хәзерге телгә тәрҗемә ителгән тексты 1989 елда басылып чыкты.



“Мөстәфадел-әхбар...” китабын кыскача татар тарихы дип атарга мөмкин. Анда татар халкының этник тарихы, мәгарифе, рухи мирасы, күренекле шәхесләре, мәчет-мәдрәсәләре хакында күп төрле мәгълүматлар бар.

*1850 нче елларда* Шиһабетдин Мәрҗанинең Каюм Насыйри, үзенең укучысы булып, зур галим дәрәҗәсенә ирешкән Хөсәен Фәезхановлар белән аралашуы мәгълүм. Мәрҗани В. Радлов, А. Казембек, И. Готвальд, В. Вельяминов-Зернов һәм башка профессорлар белән дә хезмәттәшлек итә. Казан университетында уздырыла торган гыйльми чараларда катнаша.

• 1877 елда шушы җәмгыятьнең IV Бөтенроссия корылтае уздырыла. Мәрҗани бу мәртәбәле мәҗлестә татар телендә доклад ясый.




•1884 елда “Труды IV археологического съезда в Казани” Казанда басыла.

•Шулай ук Шиһабетдин Мәрҗанинең 1879-1880 елларда Истанбул аркылы Гарәбстанга хаҗга баруы билгеле.

1867-1868 елларда Идел буе һәм Урал мөселманнарының Диния нәзарәтә Мәрҗанине Казанның ахуны һәм Мөхтәсибе итеп билгеле. Мәрҗани рәмси хакимият белән дә тыгыз элемтәләр урнаштыра. Ул Казан губернасы хакимиятнең кайбер йомышларын үти: Казан типографиямендә Коръән басылуына күзәтчелек итә җир тетрәүдән зыян күргән Каф тавы арты халыкларына  ярдәм итү өчен акча җыюны оештыра. Дәүләт учреждениеләре өчен мөселманнарның тууы, нихакы һәм вафаты турындагы мәгълүмәтларны яза, мөселманнар ант иткәндә мәхкәмә утырышларында катнаша, мөселманнарны җәнлек-хайваннарга карата мәрхәмәтле булуга чакырып, “Китап ан-насаих” (Нәсихәт китабы.-Казан, 1869) өндәмәсен яза.

Ш.Мәрҗани кулы белән язып метрика дәфтәреннән өзомтә. ТР Милли архивында саклана.






**Ш.Мәрҗанинең Казандагы йорты (хәзерге Каюм Насйри урамы, 10 йорты) һәм шәхси әйберләре**



**Мәрҗани торган йорты хәзерге күренеше**




Мәрҗани исемен белән Казанда нәшрият йорты аталган.


Издательский дом Марджани

Татарстан республикасында, Әтнә районында Коморузл авылында Мәрҗани исемендәге музей бар.




- Казанда Шиһабетдин **Мәрҗани исеменд әге** 2 нче татар гимназиясе.
- ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы ТР Фәннәр академиясенең Шиһабетдин **Мәрҗани исеменд әге**Тарих институты.
- Рәсемнәр ярышын Татарстан Республикасы Дәүләт сынлы сәнгать музее **Мәрҗани исемендәге фонд бар.**







Казанның собор мәчете

- 1889 елда 18 апрелендә Шиһабетдин Мәрҗани үлгән.
- Шиһабетдин Мәрҗани Яңа Татар бистәсе зиратында җирләнгән (Казан).





Игътибар

өчен

Рәхмәт!

